Бәзәкә авылы зиратындагы гарәп язулы кабер ташлары исемлеге
(2004 елның 2 май көнендә теркәп алынды)

1. Нәҗметдин Мөхәммәдгали угылы. 1922 ел.
2. Мөхәммәдшакир Габделкаһир угылы. 1906 ел.
3. Бибифатиха Фазлулла кызы. 1898 ел.
4. Кемгә куелганы билгесез таш. XIX гасыр ахыры.
5. Тажеддин Шәрәфеддин угылы. 1916 ел.
6. Тимергали Гайнулла угылы. 1905 ел.
7. Мөсәттика(?) Йосыф кызы. XX гасыр башы.
8. Шәмсеямал Шәриф кызы. 1901 ел.
9. Мулламөхәммәт сәүдәгәр Гыйззәтулла угылы. 1892 ел.
10. Гарифуллага куелган таш. 1894 ел.
11. Гыйльмелбәшәр Шәмселбәшәр угылы. 1898 ел.
12. Габдерәхим Әбүбәкер угылы. 1891 ел.
13. Фәтхеддин мулла Габделхәлим угылы Сәйфуллин. 1924 ел.
14. Гомәр Ибраһим угылы Балкин (Алабугалы). 1892 ел.
15. «Бөр буй Сәрдек авылының Гатиятулла бине Ишмөхәммәд. 1827 сәнә».
16. Мәрьямбикә Гайса кызы. 1878 ел.
17. Ягъкуб бине Идрис бине Баязид. 1909 ел.
18. [Мөхәммәдсалих] имам вә мөдәррис Мөхәммәдсадыйк угылы Гаделшин. 1895 ел.
19. Нигъмәтулла Гыйззәтулла угылы. 1907 ел.
20. Бәдреддин Низамеддин угылы һәм анасы Газизәгә куелган таш. 1925 ел.
21. Нигъмәтулла Гайнулла угылы. 1874 ел.
22. Бибигайшә Мөхәммәдвәли кызы. 1910 ел.
23. Миңнехәят Әхмәджан кызы. 1908 ел.
24. Низамеддин Габделвахид ~~кызы~~. 1907 ел.
25. Фатихабану мулла Мөхәммәтзакир кызы. 1912 ел.
26. Мозаффар Сәйфулла угылы. 1896 ел.
27. Әхмәдхафиз Ягъкуб угылы. 1905 ел.
28. Тажеддин Низамеддин угылы Зәйнеддинев. 1906 ел.
29. Габденнасыйр Габделгалим угылы. 1898 ел.
30. Гобәйдулла Ибраш [угылы]. 1856(?) ел.
31. Фәхерниса Габделлатыйф кызы. 1915 ел.
32. Мөхибҗамал Гаделшаһ кызы. XX гасыр башы.
33. Әхмәдгәрәй Сиражеддин угылы. 1921 ел.
34. Сахибҗамал Мөхәммәдәмин кызы. XX гасыр башы.
35. Миңлекамал Зәйнеддин кызы. 1905 ел.
36. Исламгали Габдеррәхим угылы. 1888 ел.
37. Фәрхижамал Биктимер мулла кызы. 1853 ел.
38. Сәлимә Ильяс кызы. 1824 (1834-?) ел.
39. Йөзекәйгә куелган таш. Улы Айман куйдырган. 1689 ел.
40. Зәйнелбәшәр Шонкар угылы. 1852 ел.
41. Шәмселбәшәр Зәйнелбәшәр угылы Шонкаров. 1883 ел.

*Искәрмәләр:*

– №14 ташта нәкъ шулай «Балкин» дип, «к» хәрефе белән уелган. Ихтимал, ул «т» хәрефе белән Балтин дип язылырга тиеш булгандыр. Ташны уйган кеше хаталы язган, ахрысы.

– №15 таштагы «Бөр буй Сәрдек» – хәзерге Кукмара районындагы Зур Сәрдек авылы, ул Бөр исемле елга буенда урнашкан. Вяткага коя торган Бөр елгасы Балтач районындагы Бөрбаш авылыннан башлап ага. Данлыклы Мәчкәрә авылы да Бөр елгасы буенда. Гомумән, ул төбәктәге бер төркем татар авыллары, елга исеменә нисбәт ителеп, электән үк «Бөр буе авыллары» дип йөртелгән.

– №18 ташта исеме укырлык түгел, уалган иде. «Мөхәммәдсалих» исеме архив мәгълүматлары нигезендә ачыкланды.

– №39 таш – Бәзәкә авылы зиратында хәзергәчә сакланып калган иң борынгы таш. Бу ташны беренче мәртәбә (2004 елның 2 май көнендә) күргәндә язуларын калын мүк каплаган иде, кеше исемнәрен һәм елын укый алсам да, соңгы юллары начар танылды һәм текстын төгәл генә аныклап бетерә алмаган идем. Шунлыктан, Айман бабайга атасы Йөзекәй куйдырган кебек аңлашылган иде. Алай да, бервакыт яхшылап чистартып укырга кирәк булыр дип йөрдем. Бу таш турында мәкаләләребездә телгә алган вакытта да Айман Йөзекәй улына куелган таш дип язган идем[1]. Ташъязманы 2016 елның 2 апрель көнендә яхшылап чистартып, яңадан укыдым. Чынлыкта исә, бу ташъязманы Айман Йөзекәй улы үз әтисенә – Йөзекәйгә ясатып куйдырганлыгы ачыкланды. Анда: «...тарих мең дә бер йөз ел ирде, Айман Йөзекәй угылы ирде, атасы өчен бу билгене ирәнләрдин дога өчен» дип уелган.

Архив мәгълүматларыннан ачыклавымча, ташны куйдырган Айман – минем сигезенче буындагы Тукай исемле бабамның бертуган энесе, ә Йөзекәй тугызынчы буын бабам. Ягъни, нәсел чылбырыбызның төп буыннары: Йөзекәй (?–1689) → Тукай → Даут → Әбләй → Габделмәннаф (1764–1830) → Гыйззәтулла (1801–1868) → Мөхәммәтшакир (1832–1892) → Шаһимәрдан (1856–1930) → Гыйльмегаян (1892–1982) → Фәтхелбәян (1924–1995) → Раиф (1964).

---

[1] Мәрданов Р. Бәзәкә авылы тарихына кайбер мәгълүматлар // Менделеев яңалыклары. – 2004. – 23, 30 июль; Мәрданов Р, Һадиев И. Борынгы ташлар ни сөйли? // Мәйдан. – 2006. – №8. – б. 158.